| СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>**27.06.2016** | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 99** |

2005 елның 14 декабрендәге 18 номерлы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән расланган Татарстан Республикасы “Зеленодольск муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», 2015 елның 5 октябрендәге 285-ФЗ номерлы «Россия Федерациясенең аерым закон актларына дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерә ала торган шәхси кызыксынулары барлыкка килү турында хәбәр итү бурычларын билгеләү һәм мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу чараларын күрү өлешендә үзгәрешләр кертү турында», 2016 елның 15 февралендәге 21-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында «Федераль законның 14 статьясына үзгәреш кертү турында» Федераль законнар, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 15, 99-101 статьялары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. 2005 елның 14 декабрендәге 18 номерлы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән расланган Татарстан Республикасы “Зеленодольск муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2006 елның 31 октябрендәге 96 номерлы, 2007 елның 9 июлендәге 190 номерлы, 2008 елның 10 июнендәге 313 номерлы, 2008 елның 20 октябрендәге 378 номерлы, 2010 елның 16 июнендәге 524 номерлы, 2012 елның 15 мартындагы 134 номерлы, 2012 елның 29 декабрендәге 223 номерлы, 2014 елның 21 февралендәге 361 номерлы, 2015 елның 5 мартындагы 492 номерлы, 2015 елның 28 августындагы 561 номерлы, 2016 елның 15 февралендәге 61 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1) 26 статьяда:

1.1) 5 пунктның 3 пунктчасында «кызыксыну» сүзеннән соң «(туры яисә кыек)» сүзләрен өстәргә, «объектив» сүзен «тиешле, объектив һәм гадел» сүзләренә алмаштырырга;

1.2) 6 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы "Коррупциягә каршы тору турында”, 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында», 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында» Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәгән очракта, район Советы депутаты вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла».»;

2) 59 статьяның 5.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

«Әлеге пунктның беренче абзацында каралган гарантия, даими нигездә эшләүче Район Башлыгы, аның урынбасарларының вәкаләтләре туктатылган очракта, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 35 статьяның 16 өлешендәге җиденче абзацында, 6 өлешнең 2.1, 3, 6 - 8 пунктларында, 36 статьяның 6.1 өлешенең 1 пунктында, 7.1 өлешендә, 10 өлешенең 5 - 7 пунктларында, 40 статьяның 10.1 өлешендә, 73 статьяның 1 һәм 2 өлешләрендә каралган нигезләр буенча кулланылмый.».

3) 80 статьяның 1 пунктының 5 пунктчасында «Россия Федерациясе» сүзләрен «Россия Федерациясе. Беркетмә чарасына, хезмәт командировкасына яисә башка рәсми чарага бәйле рәвештә алган, бүләкне тапшырган муниципаль хезмәткәр аны Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә сатып ала ала" сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында дәүләт теркәвенә алганнан соң (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең 101 статьясындагы 2,3 өлешләре нигезендә үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**

**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**